ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА ШАШЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОШАШИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АТНИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422008 Республика Татарстан Атнинский район с. Новые Шаши. Тел. 3-23-23

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«30» сентябрь 2024 г. № 9

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 2017 елның 28 февралендәге 2 нче номерлы карары белән расланган “Муниципаль мәгълүмат системаларының эшләве һәм алардан файдалану тәртибе турындагы нигезләмәгә” үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

"Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 2 июлендәге 360-ФЗ номерлы Федераль законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 27 гыйнварындагы 60 номерлы «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасын мәгълүмати тәэмин итү, анда документлар әйләнешен оештыру чаралары хакында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте актларының һәм аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында" гы, Татарстан Республикасы Әтнә районы прокурорының 2024 елның 28 июнендәге 02-08-02-2024/Прдп285-24 протесты нигезендә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Яңа Шашы авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Яңа Шашы авыл җирлеге башкарма комитетының «Муниципаль мәгълүмат системаларының эшләве һәм алардан файдалану тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» гы 28.02.2017 ел, № 2 карарына (08.04.2020 ел, №9, 12.05.2020 ел, №11, 06.12.2021 ел, №24 редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Карар преамбуласында "Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 28 ноябрендәге 1091 нче номерлы карары белән «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендәге төбәк һәм муниципаль мәгълүмат системаларына бердәм таләпләр турында» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 27 гыйнварындагы 60 нчы номерлы карары белән “Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасын мәгълүмати тәэмин итү, анда документлар әйләнешен оештыру чаралары хакында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте

актларының һәм аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында" сүзләренә алмаштырырга.

1.2. Нигезләмәнең 3.8 пунктын түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.8. Сатып алулар өлкәсендә муниципаль мәгълүмат системаларының эшчәнлеге һәм алардан файдалану тәртибе әлеге нигезләмә белән билгеләнә, ул Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 27 гыйнварындагы 60 нчы номерлы "Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасын мәгълүмати тәэмин итү, анда документлар әйләнешен оештыру чаралары хакында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте актларының һәм аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында" карары белән билгеләнгән үзенчәлекләрне һәм таләпләрне исәпкә алып билгеләнә. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 27 гыйнварындагы 60 номерлы карары белән расланган бердәй таләпләр "Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында" Федераль законның 4 статьясындагы 7 өлеше нигезендә муниципаль берәмлекләр тарафыннан төзелгән сатып алулар өлкәсендәге муниципаль мәгълүмат системаларына куела.

1.3. Нигезләмәнең 3.9 пунктының 3 пунктчасына "электрон мәйданчыкларда;" сүзен өстәргә.

1.4. Нигезләмәнең 4.9 пунктын түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә:

«4.9. Сатып алулар өлкәсендәге муниципаль мәгълүмат системасы, регламент һәм технологик эшләргә, мәгълүмат системасының эшенә һәм андагы мәгълүматның куллану һәм алу өчен аңлаешлы булуына тәнәфестән тыш, тәүлек буе өзлексез эшләвен тәэмин итәргә тиеш.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында http://atnya.tatarstan.ru. адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Әтнә муниципаль районы
Яңа Шашы авыл җирлеге башлыгы : М.С.Сабирҗанов